КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 декабрь г.Казань № 1138

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчегә инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналарны, күпбалалы ата-аналарны эшкә урнаштыру өчен эш урынын (шул исәптән өйдәге) булдыруга (җиһазландыруга) җиһазлар сатып алу, монтажлау һәм кую чыгымнарын каплау тәртибен раслау турында» 2013 ел, 24 май, 346 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчегә инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналарны, күпбалалы ата-аналарны эшкә урнаштыру өчен эш урынын (шул исәптән өйдәге) булдыруга (җиһазландыруга) җиһазлар сатып алу, монтажлау һәм кую чыгымнарын каплау тәртибен раслау турында» 2013 ел, 24 май, 346 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 18 сентябрь, 667 нче, 2014 ел, 16 октябрь, 765 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эш бирүчегә инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналарны, күпбалалы ата-аналарны эшкә урнаштыру өчен эш урынын булдыруга (җиһазландыруга) чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән Эш бирүчегә инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналарны, күпбалалы ата-аналарны эшкә урнаштыру өчен эш урынын булдыруга (җиһазландыруга) чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.»;

әлеге карар белән расланган Эш бирүчегә инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналарны, күпбалалы ата-аналарны эшкә урнаштыру өчен эш урынын (шул исәптән өйдәге) булдыруга (җиһазландыруга) җиһазлар сатып алу, монтажлау һәм кую чыгымнарын каплау тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин